“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында **КАРАР**

2019 елның 11 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 9 һәм 10 декабрендә гражданнар җыенының уздырылган этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау протоколы төзелде:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар) тыш, 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

• Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Дачная урамы буенча юл ремонтлау һәм вак таш җәю.»

Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау протоколы нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 609 катнашучы кертелгән, җыенда 320 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 314 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 6 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1.”Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем

алучы студентлар) тыш, 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

  - Дачная урамы буенча юл ремонтлау һәм вак таш җәю.»

3. "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан, ташламалы категорияләрдән (беренче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар) тыш, 2020 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

  - Дачная урамы буенча юл ремонтлау һәм вак таш җәю.

4. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п, Ленин ур., 8 йорт; Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т.п, Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
"Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Тенеш шәһәр
тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге
башлыгы И.Т. Гыйниятов